РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЛЕШЕВ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛӘШӘҮ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

РЕШЕНИЕ
2018 ел, 17 сентябрь

КАРАР
№ 15

## Референдум уздыруны инициацияләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Ләшәү Тамак авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

"2019 елда үзара салым кертүгә Ләшәү Тамак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 250 сум күләмендә, I төркем инвалидлардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү;
- буш вакытны оештыру һәм җирлектә яшәүчеләрне мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;
- Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урамнарның исемнәре һәм йортларның номерлары булган күрсәткечләр урнаштыруны, кече архитектура формаларын урнаштыруны һәм карап тотуны да кертеп);
- Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгы И.З.Хабибуллин